*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

Алтынчы сан

Февраль, 2015 нче ел

## Бу санда:

*Гимназия сулышы* 1

*Батырлык дәресе* 2

*Февраль – спорт, сәламәтлек, батырлык айлыгы* 3

*Иҗади сәхифә* 4

## Тормыш дәресләре

Әфганчыларны искә алу митингында 8-10 нчы сыйныф укучылары Батырлар һәйкәленә венок салдылар. Гимназиядә Әфган сугышы ветераннары Маис Шәрипов, Ренат Харрасов белән очрашу оештырылды.

Югары сыйныф укучылары арасында «Бөек Ватан сугышы тарихын иң яхшы белүче» бәйгесе узды.

Җиңүнең 70 еллыгына багышлап, 5-7 нче сыйныф укучылары өчен "Хәтерләрне яңартыйк" әдәби-музыкаль кичәсе тәкъдим ителде.

Башлангыч сыйныф укучылары Бөек Ватан сугышы ветераны Әхсән Шәриповны кунакка чакырдылар. Аның данлы сугыш юлы белән таныштылар.

Татарстан Республикасының яшь юристлар берләшмәсе әгъзалары белән очрашу файдалы үтте.

Гимназия коллективы "Татарстан чаңгы юлы" акциясендә катнашты.

# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

## 2015 НЧЕ ЕЛ - РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ



"Әдәбият елы" кысаларында гимназиядә язучылар белән очрашулар уздырыла. Күренекле прозаик, драматург, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла белән очрашуны гимназия укучылары түземсезлек белән көтеп алды. Язучы гимназия укучылары көче белән оештырылган күргәзмә белән таныштты. Укучылар түгәрәкләрдәге шөгыльләре турында сөйләделәр, өч телдә чыгарылган аудиодиск, ике телдә нәшер ителүче газеталар тәкъдим ителде. Рабит Батулла гимназия китапханәсенә үзенең тормышы, иҗаты турында китап бүләк итте. Укучылар белән очрашу барышында язучы балаларны кызыксындырган күпсанлы сорауларга җавап бирде. Батулла – бик укымышлы, зыялы шәхес. Аның биргән киңәшләре, акыллы сүзе, үткен фикерләре укучылар күңелендә озак сакланыр.

## ГИМНАЗИЯ ОЛИМПИАДА ПРИЗЕРЛАРЫН ХӨРМӘТЛИ

Башкалабыз Казанда гыйнвар-февраль айларында Бөтенроссия олимпиадаларының республика этабы үтте. Фән бәйгеләренең муниципаль этабында җиңү яулаган укучыларыбыз төрле фәннәр буенча республикада көч сынашты.

Татар теленнән республика бәйгеләрендә 9 нчы б сыйныфы укучысы Язилә Әһлиуллина һәм 11 нче в сыйныфы укучысы Алина Асманова тирән белемле икәнлекләрен исбат итә алдылар - призер булдылар. Уңышларыгыз дәвамлы булсын!

## "ЕЛ УКЫТУЧЫСЫ - 2015" ҖИҢҮЧЕЛӘРЕН ТӘБРИКЛИБЕЗ

"Ел укытучысы" конкурсының район туры җиңүчеләре билгеле булды. Җиңүче - гимназиянең биология укытучысы Бариева Л.Ф. Беренче урында - рус теле һәм әдәбияты укытучысы Арсланова Л.Н. "Иң яхшы физика укытучысы" номинациясендә җиңүче - Саяхова З.М. Без сезнең белән горурланабыз! Алдагы этапта да уңышлар юлдаш булсын!

## "АҖАГАН" ХӘРБИ-СПОРТ УЕННАРЫ – ЧЫНЫГУ МӘКТӘБЕ



Ватанны саклаучылар көненә багышлап уздырылган "Аҗаган" хәрби-спорт уеннарына гимназия укучылары җитди әзерлек белән бардылар. Монда бөтен нәрсә чынбарлыкка якын итеп уйланылган: марш җыры белән атлау, хәрбиләштерелгән спорт уеннары, чып-чын окоп, биек кар ныгытмаларын яулап алу өчен көрәш, биеклекне ялап алу, хәтта поход кухнясы да бар. Көн дәвамында җиңүләр дә күп булды, җиңелү ачысын татырга да туры килде. Шулай да, барыбыз да бу ярышлардан канәгатьләнү хисләре белән кайттык. Коллективны туплау өчен мондый ярышлар кирәк булуы бәхәссез.


## АФӘРИН, ЕГЕТЛӘР!

Гимназиядә спорт, сәламәтлек, батырлык айлыгы кысаларында «Афәрин, егетләр!» бәйгесе узды. 11 нче сыйныф егетләре, 9-10 нчы сыйныф егетләре белән көч сынашып, беренчелекне алдылар. Афәрин, егетләр!





## БАТЫРЛЫК ДӘРЕСЕ




**Әфган сугышында 546255 кеше катнашты. Шуларның 6669ы гарипләнде, 49985е җәрәхәтләнде, 312се хәбәрсез югалды, 18е чит илләрдә калды, 13833е үлде. Үлгәннәр арасында 442 кеше татар милләтеннән. Татарстаннан 256 кеше үлде. Районыбыздан бу сугышта 123 кеше катнашты. Аларның алтысы туган якларына әйләнеп кайта алмады.**

Әфган сугышыннан кайта алмаганнар исемлегендә минем әнинең абыйсы Илфар Фаррахов та бар. Илфар абыйның тормышы яшьтәшләренекеннән әллә ни аерылып тормый. 1960 нчы елда туган абыебыз Әмәкәй мәктәбендә белем ала, Күбәк мәктәбен, аннары Әлмәт төзүчеләр техникумын тәмамлый. Гармунда, гитарада бик оста уйный. Техникумны тәмамлаган көннәрдә хәрби хезмәткә чакырыла. Кулына дипломын да ала алмаган яшь егет Әфган сугышына барып керә.

Без сугыш дәһшәтен кинолардан гына күреп беләбез. Безнең гаиләгә тыныч көннәрдә сугыш югалтуын кичерергә туры килгән. Әнием үзе бу югалтуны сабый йөрәгенә сыйдырган кеше, шуңа күрә Әфган сугышы турында сүз чыкканда, ул тыныч кала алмый. Илфар абыйның әби-бабама, әниемә, Илфат абыйга атап язган хатларын без бергәләп укыйбыз. Укыган саен, алардан үземә бик күп нәрсә алам. Бер хатында болай дип язган: *“Мин Үзбәкстанда, Термез шәһәрендә хезмәт итәм. Монда бик кызу: 40-50 градус. Көн буе су эчәбез. Шәһәр “пограничный” дип атала. Әфган безнең частьтан 1,5 км гына.”* Ант кабул иткәннән соң, аларны Әфган җиренә кертәләр. Абыем андагы хәлләр турында хатларында бер сүз дә язмый. Әти-әнисен, туганнарын борчымаска тырышуы сизелә. Әниемә атап язган хатларын кабат-кабат укыйм.

*“Исәнме, Илсөяр сеңлекәш! Сиңа сагынычлы солдат сәламнәре белән абыең Илфар хат яза.*

*Минем хәлләр әйбәт. Озакламый кайтыр вакыт та җитә. Шуңа менә сиңа хат язам. Алайса бик нык ачулангансың. Бигрәк “усаллангансың” икән. Мин армиягә киткәнче дә усал идең. Һаман да шулай мени әле син, “шайтан кыз”? (шаяртам гына, үпкәли күрмә) Илфатка “көн күрсәтмисеңме”? Шаярасыздыр инде. Дус булыгыз. Мин менә сезне сагынам да, кайтырга ара ерак, Әлмәт түгел. Син хәзер бәләкәй кыз түгел инде. Әбекәйнең, әти-әнинең сүзен тыңла, яме. Гел булышып кына тор. Кара аны, әйбәт укы, кыз кешегә начар уку килешми ул, яме?! 23.10.79. Кичке 5.”* Сугыш эченнән мондый эчтәлекле, мәгънәле хатлар язу өчен күпме көч кирәк булгандыр?!

*“Һаман да шул Әфганстанда әле. Кайчан чыгу билгеле түгел. Башта парашюттан сикерә идек, хәзер күргән дә юк, башка сикерергә туры килмәс инде. Монда хәзер җәй. Кызу, кояшлы көннәр башланды. Кар тау башларында гына калды. Әфганстан матур ил икән: биек таулар, яшел үзәннәр. Аста ямь-яшел, ә тау башларында ап-ак кар ята – карап туймаслык. Иртән кояш чыкканда, әзелеп-әзелеп, өйгә кайтасы килә башлый, әле өйгә хәтле ерак шул... 20.03.1980 ел”.*

*“...Әле күптән түгел генә бокс буенча өченче разрядка, самбо буенча өченче разрядка экзамен бирдем. Мактана дип уйлама, кайткач сине дә өйрәтермен,бергәләп тренировка ясарбыз. Ә хәзергә физкультура белән шөгыльләнә тор, яме. Монда пока тыныч. Чыгару турында сөйләмиләр... 29.07.1980 ел”.*

Хатларда сугыш хәрәкәтләре турында бер сүз дә юк. Аларда туган җирне сагыну, ярату, туганнары, дуслары белән, әти-әнисе, әбисе белән күрешү теләге ярылып ята. Хатларны укыган саен, туган абыемның оптимизмына, андагы позитивлыкка сокланам. Барлык хатларында да якыннары турында кайгырту, аларны борчымаска тырышу сизелеп тора, авырлыклар арттa калуы турында яза. Һәр хатында: *“Ышаныгыз минем исән кайтуыма. Мин үземнең исән-сау кайтуыма ышанам. Әле миңа яшисе дә яшисе...”,* - дип яза. Бер уйласаң, абыем әле балалыкта гына булган, ә күңеле ирләрчә уйлый белгән. Сагынса да, авыр булса да, тешен кысып түзгән, беркемгә берни сиздермәгән...

Безнең өчен иң кадерле нәрсә – абыебызның хатлары. Үзе һәлак булганнан соң, алар гаиләнең барлык кешеләре өчен бердәнбер юаныч була. Чөнки бу хатларда әле ул исән, ул сөйли, ул туганнарын сагына, туган авылын юксына, ул тормышка планнар кора – димәк, яши!

Батырлар исеме онытылмый. Хәтер китабында Илфар Фаррахов турында мондый сүзләр бар: “Сержант, командир десантно-штурмового отделения. В Республике Афганистан с 1970 года. Проявил себя мужественным воином. В боях с противником уверенно командовал подчиненными, личным примером вдохновлял отделение на выполнение боевых задач. Погиб в бою 09.08.1980 г. Награжден орденом Красной Звезды (посмертно)”. Бу җөмләләрне укыгач, күңелемне горурлык хисе биләп ала. Абыем “намус”, “хәрби бурыч” төшенчәләрен үз тормышыннан өстен куйган, хәрби антына тугрылыклы булган. Аның каһарманлыгы, Ватанга мәхәббәте чиксез булган.

Мөслимдә “Батырлар аллеясы” булдырылгач, Әфган сугышында һәлак булган якташларыбыз истәлегенә һәйкәлләр куелды. Без анда еш булабыз, һәйкәлгә чәчәкләр куябыз, күңелләребез абый белән сөйләшә. Халык үз геройларын белергә тиеш. Сугышлар кабатланмасын! Без тыныч тормышта яшәргә хаклы!

***Мансур Миннәхмәтов,***
***7 нче б сыйныфы укучысы.***

## ФЕВРАЛЬ – СПОРТ, СӘЛАМӘТЛЕК, БАТЫРЛЫК АЙЛЫГЫ

### СПОРТ УЛ – ТОРМЫШ

Мин спортны яратам. Спортны яраткан һәм аның белән даими шөгыльләнгән кеше көчле рухлы була. Спорт белән шөгыльләнүчеләрнең гәүдәсе төз, нык була, алар башкалардан җыйнаклыгы, җитез хәрәкәтле булулары белән аерылып торалар, авыруларга бирешмиләр.

Кечкенәдән мин үзебезнең "Нептун" бассейнында оештырылган йөзү түгәрәгенә йөри башладым. Бассейнда балалар ике төркемдә шөгыльләнә: 8-12 яшькә кадәр кечкенәләр төркеме һәм 12-16 яшьлекләр төркеме оешкан. Тренерыбыз Дәүләтшин Алмаз Әмирҗан улы минем мөмкинлекләремне күреп алды һәм ярышларга махсус рәвештә әзерләндерә башлады. Тренировкалар һәр көнне була. Ярышларга барганда да, тренировкалар вакытында да "Без булдырабыз!" девизы астында йөрибез. Тренерыбыз безне физик яктан гына түгел, рухи яктан да чыныктыра. Чын күңеленнән нәтиҗәгә дип эшләүче тренерыбызны барыбыз да яратабыз, аның һәр таләбен төгәл үтәргә тырышабыз. Йөзү буенча бик матур нәтиҗәләрем бар. Район, республика ярышларында, төбәкара ярышларда шәхси җиңүләрем дә, командабыз уңышларында да өлешем күп. Яшьләргә барысына да әйтәсе килгән сүзем бар: спорт белән шөгыльләнегез, вакытыгыз бушка үтмәсен. Спорт – сәламәтлекнең нигезе!

***Миләүшә Абдуллина, 8 нче а сыйныфы укучысы.***

### МИЛЛИ КӨРӘШ – КӨЧЛЕ РУХЛЫ ЕГЕТЛӘР ӨЧЕН

Милли көрәш - бик нык ихтыяр көче сорый торган спорт төре. Борынгыдан үк килгән ярыш төре буларак, аның үзенең кагыйдәләре бар.

Без гимназиянең спорт залында оештырылган милли көрәш түгәрәгенә йөрибез. Тренерыбыз Илнар Нәфис улы Сәетгалиев белән атнага өч тапкыр шөгыльләнәбез. Ярышларга яхшы әзерлек белән килмәсәң, уңышка ирешеп булмый. Барыбыз да бу хакыйкатьне бик яхшы аңлыйбыз, шуңа күрә үзебезне формада тоту өчен тырышабыз.

Сабантуйларда җиңүче батырларны халык аеруча якын итә. Кызлар алдында да сынатасы килми. Көндәшеңне "чиста" җиңүгә ирешү өчен, ел буена туктаусыз шөгыльләнергә, чыныгырга туры килә. Бу спорт – бик көчле егетләр өчен. Түгәрәктә шөгыльләнү өчен килгән егетләрнең барысы да авырлыкларга түзә алмый: бераз йөреп карыйлар да ташлыйлар. Минемчә, монда ирләрчә нык характер формалаша. Район, республика ярышларында алган урыннар – болар барысы зур хезмәт, тир түгеп табылган тырышлык нәтиҗәсе.

Минем сыйныфташларым Нияз Хуҗин, Ленар Латыйпов, Салих Әхмәдиев, Шамил Баев, Рафаэль Иванов һәм Илназ Фәхразиев, Динар Хәсәнов – Илнар Нәфисович тәрбияләгән көрәшчеләр. Тренерыбыз үзе: "Көрәш ул – чир. Аның белән бер чирләсәң, котылып булмый", - дип әйтергә ярата. Бу дөрестер, мин үз тормышымны милли көрәштән башка күз алдына да китерә алмыйм. Без үзебезнең остазыбыздан үрнәк алабыз. Киләчәктә аның уңышларын кабатларга, остазыбызны уздырып, төрле дәрәҗәләргә ирешергә телибез.

***Ринат Сафиуллин, 8 нче а сыйныфы укучысы***

### ГИМНАЗИЯ КОЛЛЕКТИВЫ ҖИҢҮЧЕЛӘР РӘТЕНДӘ

Мөслим районы оешма-предприятияләре арасында Кышкы спартакиада уеннары 25 нче мәртәбә үткәрелде. Юбилей сезонында гимназия коллективы "Нептун" бассейны белән берлектә призер булды, премия белән бүләкләнде. Бу җиңүгә үзеннән өлеш кертүчеләргә гимназия дирекциясе рәхмәт белдерә. Афәрин, гимназия!

### ЧЫН ИР-ЕГЕТ ИТЕП ҮЗЕҢНЕ ХИС ИТӘСЕҢ КИЛСӘ...

Казан шәһәрендә 15-17 нче февраль көннәрендә "Форпост" спорт-яшьләр оешмасында шөгыльләнүче укучыларның республикакүләм ярышы булды. Безнең гимназия егетләре һәм кызлары да бу ярышларда катнаштылар. Алар нинди кичерешләр белән кайттылар икән? Әйдәгез, үзләре белән сөйләшеп карыйк.

**Риназ Харитонов:** Мин тормышымны хәрби хезмәт белән бәйләргә телим. Беренчедән, үземнең хәрби тормышка әзерлегемне сынап карау мөмкинлеге чыгуга мин бик шат идем. Икенчедән, үзем кебек яшьтәшләрем белән аралашу мөмкинлеге туды. Мондый ярышларның тагын бер әһәмияте шунда: команда тупланды. Бер-беребез өчен бөтенебез янып-көеп, уртак максатлар белән яшәдек.

**Камил Микалин:** Казармада яшәү шартларын үз җилкәбездә татып карадык. Туклану солдатларча булды. Физик әзерлек белән үткән көннән соң, ял итүләре бик рәхәт иде. Әгәр ир-егет физик яктан чыныккан икән, мондыйлар бернәрсәдән дә куркып калмый, киресенчә, үзләренең никадәр көчле рухлы икәнлекләрен исбат итәләр.

**Нияз Исмәгыйлов:** Минем өчен иң истә калганы - АК-74 автоматыннан ату булды. 10 нчы сыйныфны тәмамлагач, хәрби-спорт өйрәнүләрендә беренче мәртәбә автоматтан атып караганыбыз бар иде. Кыр шартларында карга ятып ату вакытында үзеңне чын сугыш кырында кебек хис итәсең. Бу кичерешләрне сүз белән аңлатып бетереп булмый – аны күрергә, тоярга кирәк. Чын ир-егет итеп үзеңне хис итәсең килсә, хәрби кеше булырга кирәктер, минемчә.

**Хафизов Рамил:** Мондый ярышларда бердәмлек күп нәрсәне хәл итә. Бездә җиңү теләге көчле иде. Бу ярышлар күп нәрсәгә өйрәтте. Үз кимчелекләребезне, җитешсезлекләребезне аңладык. Казанда үткән бу көннәр солдат хезмәтенең бөтен авырлыгын күз алдына китерергә мөмкинлек бирде.

**Чулпан Хамматова**: "Фортпост" Мөслим бүлегенең җитәкчесе - Илнур Сабиров. Без ел дәвамында җитәкчебез белән автомат сүтеп җыю, төз ату, маршировка белән шөгыльләнәбез, спортның хәрби төрләре буенча осталыгыбызны арттырабыз. Мондый әзерлек барлык егетләр өчен дә кирәк дип уйлыйм. Кызлар өчен дә рәхәтләнеп шөгыльләнергә мөмкинлекләр бар. Монда кыз-малайларга бүленеш тә, нииндидер өстенлекләр дә юк. Барыбыз да бер үк төрле бурычларны тормышка ашырабыз, бер максатка эшлибез. Мин үземне физик яктан хәзерлекле кеше итеп хис итәм.

***Укучылар белән 8 нче а сыйныфы укучысы Язилә Исмәгыйлова сөйләште***

# ИҖАДИ СӘХИФӘ

## МЕНӘ ШУНДЫЙ МИНЕМ ӘТИ!

Минем әтием - Вильданов Шакирҗан Салих улы, 1965 елның 6 июлендә Каенсаз авылында гаиләдә алтынчы бала булып туа. Әтием армия хезмәтен Венгриядә үтә. Аннан кайткач, Мәскәү өлкәсендә прапорщиклар әзерли торган мәктәптә укып, Ерак Көнчыгыш якларына хәрби хезмәткә җибәрелә. 12 ел Приморье өлкәсендә Раздольное поселогында хезмәт итә. Военкоматта да эшли. Үзенең киңәшләрен биреп, хәрби хезмәткә җибәргән егетләр, бүген дә килеп, аңа рәхмәт әйтәләр. Минем әтием гомерен хәрби хезмәткә багышлады. Россиянең бик күп өлкәләрендә, соңгы вакытта Самара шәһәрендә хезмәт итеп, 25 ел хезмәт юлын тутырып, лаеклы ялга чыкты.

Мин әтием белән бик горурланам. Ул максатчан кеше, кулыннан килмәгән эше юк, яхшы күңелле, һәрвакыт ярдәмгә килүче ышанычлы терәгебез. Минем дә хәрби хезмәткә барып, әтием кебек намуслы хезмәтем белән илебезне саклауда өлешемне кертәсем килә. Без, әтиемнең өч улы, әтиебезнең йөзенә кызыллык китермәбез, дип уйлыйм.

***Шамил Вилданов,***
***2 нче б сыйныфы укучысы***

## САГЫШ

Кырык бернең июнь ае
Илгә сугыш китергән.
Күпме балаларны ул көн
Ятимлектә үстергән.
“Сугыш” дигән ул ят сүздән
Күңелләр өшеп китә.
Данлы җиңү көнен көтеп,
Күпме гомерләр үтә...

***Ринат Мотавалов,***
***11 нче а сыйныфы укучысы***

## ТУРГАЙ ТЫКРЫГЫ

Нурдидә әби, иртәнге эшләрен тәмамлап, өйгә кергәндә, кояш шактый күтәрелгән иде инде. Өй эче кояш нурлары белән яп-якты булган. Килене эшкә киткәнче, бөтен җирне җыештырып киткәнгә, йорт балкып тора. Аллага шөкер, уңды Нурдидә әби килененнән. Аш-суга да оста, йорт-җирне дә тәртиптә тота, “әнкәй” дип өзелеп тора. Шатлык өстенә шатлык өстәп, оныгы Айгөл үсеп килә. Бик зиһенле бала булыр, ахры, дип уйлап, әби оныгына күз ташлады. Тегесе рәхәтләнеп йоклый иде әле. Нурдидә әби аны үзенең әнисенә охшата. Шундый ук кара бөдрә чәчләр, карлыгандай кара күзләр, елмаюлары – барысы да әнисенеке кебек. Бәхете генә була күрсен! Шуларны уйлап, Нурдидә әби алгы якка чыгып, чәй куеп җибәрде. Ипиен, шикәрен алырга дип, шкаф янына килүгә, күзләре ирексездән тәрәзәгә төште. Күршесе Камилә карчык тыкрыкта кычыткан җыеп йөри икән. Менә хикмәт! Бу хәл сәер булып тоелды аңа. Соңгы елларда тыкрыкта кеше заты бик сирәк күренә иде. Кычыткан җыючы да сирәгәйде шул. Авыл халкы шәһәрләшеп ята, мал асрамый диярлек. Элек тыкрыкларда бер кычытканны да калдырмый җыеп бетерәләр иде. Ә хәзер әнә анда үтүчеләр дә сирәк. Инешкә төшүче дә юк. Һәркемнең диярлек өенә су кергән. Керне дә машина юып, чайкап бирә. Ә бит заманасында бу тыкрык гөрләп тора иде. Иртә таңнан яшь киленнәр суга төшә. Ял җитсә, кер чайкарга төшүчеләр өзелеп тормый. Кышларын каз, үрдәк өмәчеләре тезелешеп, шаугөр килеп, инешкә юнәләләр иде. Мал суйсалар, ирләр-хатыннар эчәге юарга төшә. Ирләр боз өстендә ап-ак булганчы эчәгеләрне таптый, хатыннар бәкедә бөртекләп юалар, берсен дә әрәм итмиләр. Уен-көлкедән су буе шаулап тора. И-и-и, күңелле дә чаклар булган икән.

Камилә әбине тыкрыкта күрү бөтенләй күңелен кузгатып җибәрде Нурдидә әбинең. Хәер, кичә үк кузгалды инде ул күңел дигәннәре. Оныгы Айгөл инде. Бөтен нәрсә белән кызыксына торган тиктормас оныгы: “Әбием, бу тыкрыкны ни өчен “Тургай тыкрыгы” диләр?” - дип, телсез калдырды. Оныгының соравы төнлә дә тынгы бирмәде әбигә. Иртәнге эшләр белән онытылып торган иде, менә тагын кылт итеп исенә төште. Яраткан бабасы, әтисе, агалары күз алдыннан үтте.

Әйе, бик көчле, тырыш иде аларның нәселләре! Гомер буе хезмәттә булдылар, тырышып дөнья көттеләр. Абзар тулы мал-туар, кош-корт булды.

Нурдидә әбинең бабасы Шәйхәттәр карт үзе дә тынгысыз иде, балаларын да шуңа өйрәтте. Эшнең тәмен белә иде ул. Һәр эшне җае белән, яратып, булсынга дип эшли. Көндезге ашка кайткач, бөтен мал-туарын тыкрык аша инешкә су эчәргә алып төшә. Нурдидәне дә үзе белән ала. Шакката иде кыз бу күренешкә. Бабасы алдан бара, сыерлар, бозаулар, сарыклар, бер адым да читкә тайпылмыйча, аның артыннан ияреп төшәләр. Туйганчы су эчкәннән соң, тагын тезелешеп, абзарга үз урыннарына кайталар. Ә бабасы барганда да, кайтканда да көйли-сызгырына иде. Бу гади генә сызгыру түгел. Күңелләргә үтеп кererлек бер моң иде. Нәни Нурдидә үзе дә кабатларга тырышып карады ул чакта. Бабасының сызгыруын бөтен күрше-тирә ишетә һәм аны тургай сайравына охшата. Бабасы, сызгырына-сызгырына, мал эчертергә төшкәндә, “Әнә тургай сайрый башлады инде!”- диләр иде.

Бабасы авырый башлагач, әтисе дә малларны шул ук тыкрыктан нәкъ аныңча итеп йөртте. Хәзер менә улы Хәйдәр... Менә шуннан кушылды да калды инде бу тыкрыкка “Тургай тыкрыгы” дигән исем. Шуңа бик ярата тыкрыкны Нурдидә әби. Үткән саен, бабаларын, әтисен искә төшерә ул. Уйлап карасаң, гасырдан артык тарих икән бит. Нәни Айгөленә шуларны сөйләр ул бүген. Тыкрык язмышы аларга каласы бит...

Кадерле истәлекләрдән күңеле күтәрелеп китте карчыкның. Үз эченнән нидер көйли-көйли, коймак тугларга тотынды.

***Нәзилә Сарварова, 10 нчы а сыйныфы укучысы***

ТЫЛСЫМ+
**Февраль, 2015 нче ел**
***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлова Язилә
**Корректор:** Мөхәммәтханова Айгөл,
**Корреспондентлар:** Абдуллина Миләүшә, Ринат Сафиуллин
**Дизайнер:** Хәбибуллин Руслан

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Ринат Сафиуллин
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym